Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Килдураз авыл җирлегенең Килдураз авылында гражданнар җыены карары

17.11.2022 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Килдураз авыл җирлегенең Килдураз авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2023 елда Килдураз авыл җирлегенең Килдураз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 1000 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Килдураз авылында юлларны ремонтлауга, юлларны кардан чистартуга (хезмәтләр һәм килешү буенча эшләр өчен түләү) юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Килдураз авыл җирлегенең Килдураз авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Килдураз авыл җирлеге башлыгы _________ З.З. Әхәтов

Халык җыены секретаре _________ А.Н. Юнысова